**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йорт. Тел. 3-44-44

**ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел. 3-44-44

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

_______ 11.02.2025 № ПГ-2 № ____

Актаныш муниципаль районы Башлыгының «Наркотикларга каршы комиссия турында» 2014 елның 14 февралендәге ПГ-12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Наркотик чараларның, психотроп матдәләрнең һәм аларның прекурсорларының законсыз әйләнешенә каршы тору өлкәсендә муниципаль идарәне камилләштерү максатларында, РФ Президентының "Наркотик матдәләрнең, психотроп матдәләрнең һәм аларның прекурсорларының законсыз әйләнешенә каршы тору буенча өстәмә чаралар турында" 2007 елның 18 октябрендәге 1374 номерлы Указына таянып,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында наркотикларга каршы комиссия турындагы Нигезләмәне яңа редакциядә, 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Актаныш муниципаль районы Башлыгының «Наркотикларга каршы комиссия турында» 2014 елның 14 февралендәге ПГ-12 номерлы карарына 1 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмати порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында: http:/aktanysh.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль район Башлыгы Л.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башлыгы карарына
________ № ____
1 нче кушымта

Актаныш муниципаль районында наркотикларга каршы комиссия турында нигезләмә

1. Актаныш муниципаль районында наркотикларга каршы комиссия (алга таба - Комиссия) Актаныш муниципаль районының кызыксынган структур бүлекчәләренең наркотиклар һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнешенә һәм таралышына каршы тору, аларны медицина булмаган куллануны кисәтү өлкәсендәге эшчәнлеген координацияли, шулай ук районда наркоситуация үсешен бәяли.

2. Комиссия үз эшен Татарстан Республикасының наркотикларга каршы комиссиясе, федераль, республика башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары, шулай ук ведомство карамагындагы учреждениеләр, предприятиеләр, оешмалар, оештыру-хокукый формалар һәм милек формалары белән берлектә оештыра.

3. Комиссия үз эшчәнлегендә таянып эш итә:

- Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе белән;
- федераль һәм республика законнары белән;
- Россия Федерациясе Президенты указлары һәм күрсәтмәләре белән;
- Татарстан Республикасы Рәисе (Башлыгы) указлары һәм күрсәтмәләре белән;
- Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм күрсәтмәләре белән;
- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре белән;
- Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссия карарлары белән;
- Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең карарлары һәм күрсәтмәләре белән;
- Россия Федерациясендә наркотикларны контрольдә тоту буенча дәүләт сәясәте концепциясе нигезләмәләре;
-Нигезләмә белән.

4. Комиссиянең төп бурычлары булып:

- район территориясендә наркотиклар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорларының законсыз әйләнешенә каршы тору өлкәсендә дәүләт сәясәтен формалаштыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашу.
- наркотик матдәләрне, психотроп матдәләрне һәм аларның прекурсорларын явызларча куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы тору чараларын эшләү, шул исәптән әлеге әйләнешне профилактикалау, шулай ук бу өлкәдә муниципаль максатчан программаларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген арттыру чараларын эшләү;
- Актаныш муниципаль районының кызыксынган структур бүлекчәләре эшчәнлеген координацияләү, республика һәм федераль министрлыклар һәм ведомстволарның территориаль органнары, иҗтимагый һәм дини оешмалар, Россия Федерациясенең һәм БДБ илләренең эре шәһәрләре муниципаль берәмлекләре белән үзара хезмәттәшлек итү;

- наркотиклар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорларының законсыз әйләнешенә каршы тору буенча җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә анализ;
- наркотикларны явызларча куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы тору буенча закон чыгару һәм башка норматив хокукый актларны камилләштерү турында билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр әзерләү һәм кертү;
- наркомания һәм токсикомания таралуны профилактикалау эшен оештыруда кызыксынган иҗтимагый оешмаларның һәм хәрәкәтләрнең көчләрен берләштерү;
- районда наркоситуация турында мәгълүматны мониторинглау, аның үсешен бәяләү, әзерләү, аны Татарстан Республикасының наркотикларга каршы комиссиясенә тапшыру, шулай ук вәзгыятьне яхшырту буенча тәкъдимнәр.

5. Үз бурычларын үтәү өчен Комиссия:

- Актаныш муниципаль районында наркотик ситуациягә комплекслы анализ ясый һәм наркотик матдәләрне артык куллануга, аларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш буенча тиешле чаралар эшләүне тәэмин итә;
- Актаныш муниципаль районында наркомания һәм токсикомания таралуны профилактикалауга, наркотиклар куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы торуга юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган муниципаль комплекслы программаларның үтәлешен һәм аларны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган акчаларның максатчан кулланылуын тикшереп тора;
- югарыда күрсәтелгән чараларны үз эченә алган муниципаль комплекслы программаларны башкаручылардан бүлеп бирелгән акчаларның файдаланылуы турында белешмәләр соратып ала;
-район учреждениеләре эшчәнлеген оештыру, координацияләү, камилләштерү һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү турында үз компетенциясе чикләрендә җирле үзидарә органнары тарафыннан үтәлүе мәҗбүри булган һәм ведомствога карамыйча учреждениеләр, предприятиеләр, оешмалар, берләшмәләр, оештыру-хокукый рәвешләр һәм милек рәвешләре өчен тәкъдим ителгән карарлар кабул итә;
- дәүләт, иҗтимагый һәм башка оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан аның эшчәнлеге өчен кирәкле документларны, материалларны һәм мәгълүматны соратып ала, шулай ук комиссия эшендә катнашу өчен вазыйфаи затларны һәм белгечләрне җәлеп итә (килешү буенча);
- үз утырышларында Актаныш муниципаль районы җирле үзидарәсе вазыйфаи затларын Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тыңлый;
- наркотик матдәләрне явызларча куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы тору өлкәсендә муниципаль норматив хокукый актлар проектларын карый, аларның эчтәлеге буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертә;
- Комиссия эшчәнлегенең аерым аспектлары буенча документларны һәм карарларны оператив һәм сыйфатлы әзерләү өчен белгечләрдән вакытлы эш төркемнәре төзи.

6. Комиссия рәисе, шәхси составы һәм секретаре Актаныш муниципаль районы башлыгы карары белән раслана.

7. Рәис комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә утырышлар үткәрә, утырышларның беркетмәләренә имза сала, Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча комиссия секретарена һәм әгъзаларына йөкләмәләр бирә.

8. Тиешле дәүләт органнары, фәнни һәм иҗтимагый оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары тәкъдиме буенча комиссия составына аларның вәкилләре кертелергә мөмкин.

9. Комиссия үз эшчәнлеген комиссия утырышында кабул ителә торган һәм аның Рәисе тарафыннан раслана торган бер елга эш планы нигезендә гамәлгә ашыра.

9. Комиссия утырышлары квартал саен уздырыла. Утырышларның көн тәртибен һәм аларны үткәрү тәртибен комиссия рәисе билгели.

10. Комиссия утырышында аның әгъзалары булу мәҗбүри. Әмма алар үз вәкаләтләрен комиссия рәисе белән килештереп башка затларга тапшыра алалар. Монда булу мөмкин булмаган очракта, комиссия рәисенә алдан язма рәвештә хәбәр итәргә. Утырышта комиссия әгъзасы булмаган очракта, ул карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы.

11. Комиссия утырышта аның әгъзаларының кимендә өчтән икесе катнашса (Комиссия әгъзалары – көн тәртибендәге мәсьәләләр каралган структуралар һәм ведомстволар җитәкчеләре мәҗбүри катнашканда) мәсьәләләрне хәл итәргә хокуклы.

12. Утырышта карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышканда комиссия әгъзалары тигез хокукларга ия була. Комиссия карарлары утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм комиссия рәисе имзалый торган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Кабул ителгән карар белән килешмәгән очракта комиссия әгъзасы үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул утырыш беркетмәсенә һичшиксез беркетелергә тиеш. Тавышлар тигез булганда, Рәиснең тавышы хәлиткеч була.

13. Комиссия эшендә кирәк булганда дәүләт органнарының һәм иҗтимагый оешмаларның аның составына керми торган вазыйфаи затлары катнаша ала.

14. Комиссия эшен оештыру-техник һәм мәгълүмати тәэмин итү секретарьга йөкләнә, кирәк очракларда – комиссия составына кергән Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының аерым структур бүлекчәләренә.

15. Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән бурычларны тормышка ашыру максатыннан, Комиссия Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре белгечләреннән һәм җәмәгать эшлеклеләреннән вакытлы эш төркемнәре төзи ала.

16. Комиссия эшчәнлеген мәгълүмати-аналитик тәэмин итүне Актаныш муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләр башкара.